ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2022 г. Заинск № 620

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мобилизацияле әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен исәпләү, билгеләү һәм аның күләмен үзгәртү тәртибе» (2022 елның 08 июлендәге 337, 2022 елның 23 маендагы 249, от 03.10.2022 елның 03 октябрендәге 506 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2 нче кушымтасының II өлешенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Бишенче абзацның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән, йә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт төзегән, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнарның балалары өчен ата-ана түләве алынмый (ата-анадан (законлы вәкилдән) бирелгән гариза һәм хәрби комиссариат белешмәсе нигезендә)».
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдщ тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42